# КАРАР

**2019 елның 29 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок Сутер авылында Ленин, Бакча, Яшьләр, Яңа урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау: проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек;
- Починок Сутер авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Починок Сутер авылында Яшьләр урамына янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;
- Починок Сутер авылында урамнарны яктыртуны карап тоту;
- Починок Сутер авылында шлагбаум урнаштыру: проект-смета документлары;
- Починок Сутер авылында спорт мәйданчыгы төзү өчен мәйданчыкны тигезләү һәм планлаштыру: проект-смета документациясе?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 213 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 132.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 132 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге Починок Сутер авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлегенең Починок Сутер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Починок Сутер авылында Ленин, Бакча, Яшьләр, Яңа урамнарында вак таш җәеп, юллар төзү һәм ремонтлау: проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек;
- Починок Сутер авылында юлларны җәен һәм кышын карап тоту һәм чистарту;
- Починок Сутер авылында Яшьләр урамына янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру;
- Починок Сутер авылында урамнарны яктыртуны карап тоту;
- Починок Сутер авылында шлагбаум урнаштыру: проект-смета документлары;
- Починок Сутер авылында спорт мәйданчыгы төзү өчен мәйданчыкны тигезләү һәм планлаштыру: проект-смета документациясе?

«РИЗА» «КАРШЫ»
- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче,
Важашур авыл җирлеге башлыгы П.Л. Иванов